**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«01» ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалид булганнардан тыш, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгәгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Рус Богдашкиносы авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм вак таш һәм грунт катнашмасы салу (сатып алу, ташу, җәю);

- Урам утларын ремонтлау һәм карап тоту (кирәкле материал алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре).

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы торак пунктында суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче: А. Л. Михайлова

Богдашкино авыл җирлеге башлыгы А.Л. Михайлова